РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» март 2026 ел г. Альметьевск № 441

Әлмәт муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында Әлмәт муниципаль районы Уставы белән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар итеп билгеләргә:

- гомуми файдаланудагы территорияләр (шул исәптән чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана торган мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, скверлар һәм башка территорияләр);
- күпфатирлы йортлар янындагы территорияләр;
- балалар уеннары һәм спорт мәйданчыклары;
- актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;
- массакүләм чаралар үткәрү өчен мәйданнар;
- балалар, мәгариф, дини һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
- мәдәният объектларына якын территорияләр;
- җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә челтәрләре объектлары һәм калдыклар туплау урыннары (мәйданнары) янындагы территория.

2. Әлмәт муниципаль районы территориясенә хуҗасыз хайваннарны

заказ № 4553-940

элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле зат итеп «Экология һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары А. Г. Голосовны билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый м әгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. А. Габдуллинга йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов